**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«10» 03 2022 Яр Чаллы шәһәре № 695

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең 16:39:100103:72 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 17 маендагы вн/3 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, район уставы, «Якты юл» («Светлый путь») газетасында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган 2022 елның 24 гыйнварендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең 16:39:100103:72 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Шәхси хуҗалык алып бару» төп төрдән «Дини объект» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртергә.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары О.А. Никитинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин